**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь 1033

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче, 2015 ел, 22 август, 612 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (алга таба – ТР ССМ);»;

«Татарстан Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – ТР ЯЭһСМ).»;

6 пункт таблицасына түбәндәге эчтәлекле 29 пунктча өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «29. | ТР ХЭТИһСЯМ | Җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан ким булган гаиләләрдән балага айлык пособие билгеләнгән 4 – 17 яшьлек (17 яшьне кертеп) балалар реестры | электрон | хисап аеның 20 сенә кадәр | ТР ССМ, ТР ЯЭһСМ». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1033.docx